**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**01.06.2018** **№ 1158**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 14 мартындагы 585 номерлы карары белән расланган Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә гариза бирүче тарафыннан бердәм гариза бирү юлы белән берничә дәүләт (муниципаль) хезмәте күрсәтү мөмкинлеген беркетү өлешендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 14 мартындагы 585 номерлы карары белән расланган Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча Биектау муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.4 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның техник шартларын билгеләү һәм бирү кагыйдәләрен һәм капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 февралендәге 83 номерлы карары (алга таба –83 номерлы карар) (РФ Законнар җыентыгы, 20.02.2006, №8, 920 ст.);»

1.2. 2.5 пунктның 2 баганасындагы 1 пунктта «ике нөсхәдә» сүзен

1.3. 2.9. пунктның 2 баганасындагы 3 пунктта эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«ГПЗУ дубликатын бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

Мөрәҗәгать итүче җир кишәрлегенә хокук иясе булып тормый һәм ГПЗУ алу

өчен хокук иясеннән тиешенчә рәсмиләштерелгән вәкаләтләргә (йөкләмәгә) ия түгел»;

1.4. 3.5 пункт

а) 3.5.1. пунктчаның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын яисә җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләүдән баш тарту турында хат проектын Башкарма комитет җитәкчесе имзасына (ул вәкаләт биргән затка).»;

б) 3.5.1. пунктчаның 4 абзацын төшереп калдырырга;

в) 3.5.1. пунктчаның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар соратуларга җаваплар кергән вакыттан алып дүрт эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

г) 3.5.2. пунктчаның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитет җитәкчесе (ул вәкаләт биргән зат) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын имзалый һәм мөһер куя яисә җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләүдән баш тарту турындагы хатка кул куя һәм Бүлек белгеченә җибәрә.»;

д) 3.5.2. пунктчаның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы яисә җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләүдән баш тарту турында имзаланган хат;»;

1.5. 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнарның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, яки дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, шулай ук дәүләт хезмәтләрен күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) гариза бирүченең судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы;

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы Башкарма комитет хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр тәртиптә Башкарма комитетка, яки муниципаль берәмлек Советына шикаять белдерү хокукына ия.

Гариза бирүче түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризасын теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары бозылу;

3) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Биектау муниципаль районы хокукый актлары белән каралмаган документларны яисә мәгълүматны яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль районның башка норматив хокукый актлары

белән баш тарту нигезләре каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы норматив-хокукый актлары белән билгеләнмәгән түләүне таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә хата-ялгышларны вакытында төзәтмәве;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакыты яисә тәртибе бозылу;

9) туктатып тору нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору.

5.2. Муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять кәгазь чыганакта яисә электрон рәвештә язма рәвештә бирелә.

Шикаятьне почта аша, күпфункцияле үзәк аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Биектау муниципаль районының рәсми сайтыннан (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасының Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга яисә югары органга (булган очракта) кергән шикаять аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган гариза бирүчедән документлар кабул итүдән яисә җибәрелгән ялгыш һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылу шикаять ителгән очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә каралырга тиеш;

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең исем-атамасы;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы(-лары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителүче карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә муниципаль хезмәткәрнең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвенә нигез булган дәлилләр.

5.5. Шикаятьтә тасвирланган хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре шикаятькә кушымта итеп бирелергә мөмкин. Мондый очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять муниципаль хезмәт күрсәтүче тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар һәм ялгышларны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланганда, шикаятьне карап тикшерү буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы Д.И. Зәйнетдиновка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин